ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕАТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная , д. 2а, д.Нижние Аты ,
Арский муниципальный район, 422006

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Узәк урамы, 2а йорт, Түбән Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422016

Тел. (84366)507-35, факс (84366)507-35 E-mail: Sat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 6 » февраль 2023 ел №3**

**«Урта Аты авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 № 27 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Урта Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Аты авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Урта Аты авыл җирлеге Советының 08.08.2022 № 69 карары нигезендә, 16.11. 2022 №1, 16.11. 2022 №2, 17.11. 2022 №3, 18.11 2022 №4, җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Арча муниципаль районы «Урта Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымы чараларын җыю тәртибе турында» Урта Аты авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 № 27 карары белән расланган Арча муниципаль районы «Урта Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 һәм 4 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм түбәндәге адреслар буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында

урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Түбән Аты авылы, Үзәк ур., 2а йорт; ТР, Арча районы, Урта Сәрдә авылы, Үзәк ур., 70А йорт ,РТ,Арча районы ,Кылачы авылы ,Аяк киеме урамы ,17 йорт .

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Урта Аты авыл җирлеге башлыгы Батталова Р.Х